РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Исполнительный комитет Варваринского сельского поселения**
Камско-Устьинский район,
с. Варварино, 422825
тел./факс 8(84377)32-6-09
ОГРН 1061672020552
ИНН/КПП 1622004764/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районының**
**Варварино авыл җирлеге Башкарма комитеты**
Кама Тамагы районы,
Варварино авылы, 422825
тел./факс 8(84377)32-6-09
ОГРН 1061672020552
ИНН/КПП 1622004764/162201001

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«17» октябрь 2019 ел** **№ 31**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 14 декабрендәге 8 номерлы «Васыятьнамәне яки ышанычнамә таныклыгын раслау турындагы нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» гы карары белән расланган нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында»**

Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 16.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 1999 елның 26 июлендәге 226-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 14 декабрендәге 8 номерлы

«Нотариаль гамәлләр кылу: васыятьнамә яки ышаныч таныклыгын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында: ышанычнамә таныклыгы бирү (күчемсез милек белән эш итүгә ышанычнамәдән тыш)»;

1 п. «васыятьнамә таныклыгы яки» сүзләрен бетерергә «ышаныч таныклыгы» сүзләреннән соң «(күчемсез милек белән эш итүгә ышанычнамәдән тыш)» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Варварино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 14 декабрендәге 8 номерлы «Нотариаль гамәлләр кылу: васыятьнамә яки ышаныч таныклыгын раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты: ышаныч таныклыгы бирү (күчемсез милек белән эш итү буенча ышанычнамәдән тыш)»;

1.1 пунктында «нотариаль гамәлләр кылу буенча: васыятьнамәне яки ышаныч таныклыгын» сүзләрен «нотариаль гамәл кылу буенча: ышанычнамә таныклыгын (күчемсез милек белән эш итүгә ышанычнамәдән тыш) " сүзләренә алмаштырырга.)»;

1.5 п. икенче абзацны төшереп калдырырга;

2.1 п. «нотариаль гамәлләр кылу буенча васыятьнамә таныклыгы яки ышаныч таныклыгы» сүзләрен «нотариаль гамәл кылу буенча ышанычнамә таныклыгы бирү (күчемсез милек белән эш итүгә ышанычнамәдән тыш)" сүзләренә алмаштырырга.)»;

2.3 п. «нотариаль гамәлләр кылу-васыятьнамә таныклыгын яки ышаныч таныклыгын» сүзләрен «нотариаль гамәл кылу-күчемсез милек белән эш итүгә ышанычнамә таныклыгыннан тыш)» сүзләренә алмаштырырга.);

2.4 п. «васыятьнамә таныклыгы яки» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.5 п. да «ышанычнамә таныклыгында» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.10 п. 4, 5 пунктчаларны төшереп калдырырга;

3.3.1 п. «васыятьнамәләр таныклыгы буенча һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.4.1 п. «васыятьнамәнең нотариаль таныклыгы яки» сүзләрен төшереп алдырырга.

2. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Көрәле авылы, Үзәк урамы, 2а;

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Варварино авылы, Ленин урамы,32 , шулай ук хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Варварино авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Т. Нотфуллин**